КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 12 апрель г.Казань № 241

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту һәм Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен кертү буенча проект офисын төзү турында» 2016 ел, 4 май, 278 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 27 июль, 511 нче; 2016 ел, 16 декабрь, 936 нчы; 2017 ел, 8 июнь, 363 нче; 2017 ел, 16 август, 584 нче; 2018 ел, 17 гыйнвар, 15 нче; 2018 ел, 25 июнь, 512 нче; 2019 ел, 22 май, 428 нче, 2019 ел, 6 декабрь, 1116 нчы, 2020 ел, 6 апрель, 259 нчы, 2020 ел, 19 декабрь, 1164 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту һәм Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен кертү буенча проект офисы составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Шакиров Динар Рәфыйк улы вазыйфасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары, проект офисы секретаре».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү буенча уңышлы тәҗрибәләрне һәм инициативаларны сайлап алу буенча ведомствоара региональ комиссия төзү турында» 2018 ел, 12 сентябрь, 770 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 1 август, 638 нче, 2019 ел, 26 октябрь, 963 нче, 2020 ел, 06 апрель, 259 нчы, 2020 ел, 19 декабрь, 1164 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасын социаль-икътисадый

үстерү буенча уңышлы тәҗрибәләрне һәм инициативаларны сайлап алу буенча ведомствоара региональ комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Ведомствоара төбәк комиссиясе составына Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Хәдиуллин Илсур Гәрәй улын кертергә;

Шакиров Динар Рәфыйк улы вазыйфасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары, ведомствоара төбәк комиссиясе секретаре».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин